**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«09» 02 2022 ел Яр Чаллы № 288

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү һәм юлларны тикшерү буенча комиссия нигезләмәсен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе турында» 2006 елның 30 октябрендәге 529 номерлы карарын (2007 ел 27 сентябрь 513 номерлы, 2007 ел 29 декабрь 765 номерлы, 2008 ел 14 май 311 номерлы, 2008 ел 5 декабрь 866 номерлы, 2009 ел 24 апрель 263 номерлы, 2010 ел 19 январь 18 номерлы, 2010 ел 9 июнь 458 номерлы, 2010 ел 13 август 656 номерлы 2010 ел 6 декабрь 1001 номерлы, 2011 ел 10 май, 372 номерлы, 2012 ел 4 апрель, 270 номерлы, 2012 ел 1 июнь 462 номерлы, 2012 ел 20 октябрь 877 номерлы, 2013 ел 17 апрель 259 номерлы, 2013 ел 7 октябрь 731 номерлы, 2013 ел 23 январь 32 номерлы, 2015 ел 3 март 129 номерлы, 2015 ел 31 июль 553 номерлы, 2016 ел 10 декабрь 915 номерлы, 2017 ел 3 июнь 334 номерлы, 2018 ел 16 май 370 номерлы, 2009 ел 13 сентябрь 823 номерлы, 2020 ел 25 ноябрь 1060 номерлы, 2021 ел 21 июль 625 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары редакциясендә) үтәү йөзеннән, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196 - ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль закон, шулай ук Россия Федерациясе транспорт министрының 1997 елның 8 январендагы 12 номерлы боерыгы белән расланган «Автобусларда пассажирлар йөртү иминлеген тәэмин итү турында нигезләмә»гә таянып, Тукай муниципаль районы территориясендә юлларның торышын һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатында,

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү һәм юлларны тикшерү буенча комиссия нигезләмәсен раслау турында» 2017 елның 21 мартындагы 600 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
2. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү һәм юлларны тикшерү буенча район комиссиясе турында нигезләмәне 1 кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе А. Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның «04» февралендәге ____ номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча комиссиясе нигезләмәсе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү комиссиясе (алга таба - Комиссия) башкарма хакимиятнең федераль органнары, Тукай районының җирле үзидарә органнары территориаль бүлекчәләр, төрле оештыру-хокукый формаларындагы оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүче, Тукай муниципаль районы территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча тәкъдимнәр әзерләүгә һәм аларны карауга юнәлдерелгән даими коллегиаль, координация органы булып тора.

1.2 Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе Президенты, Татарстан Республикасы Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карарлары һәм боерыкларына, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3 Комиссия Тукай муниципаль районы Башкарма комитетыҖитәкчесе карары белән төзелә.

## II. Комиссиянең төп бурычлары

2.1 Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә федераль башкарма хакимият органнарының, Тукай муниципаль районы җирле үзидарә органнарының территориаль бүлекчәләренең, төрле оештыру-хокукый формачындагы оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

2.2 Юл хәрәкәте иминлегенең мөһим аспектлары өстендә эшләү: машина йөртүчеләрнең һәм җәяүлеләрнең куркыныч тәртибен кисәтү, балалар арасында юл-транспорт имгәнүләрен киметү, транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен оештыруны камилләштерү, шулай ук җирле үзидарә органнары, күзәтчелек органнары, төрле оештыру-хокукый формадагы оешмалар эшенең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә нәтиҗәлелеген арттыру.

2.3 Транспорт чараларының авария хәлен кисәтүгә, гражданнарның гомерен һәм сәламәтлеген саклауга һәм юл-транспорт һәлакәтләреннән килгән зыянны киметүгә

юнәлдерелгән максатчан программалар һәм чараларны эшләү һәм гамәлгә ашыру буенча Тукай муниципаль районында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль бүлекчәләре, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының җирле үзидарә органнары һәм төрле оештыру-хокукый формадагы оешмалар эшчәнлеген координацияләү.

2.4 Тукай муниципаль районы территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә норматив хокукый актларның үтәлешен контрольдә тотуны оештыру.

## III. Комиссия функцияләре

3.1 Тукай муниципаль районы территориясендә транспорт чараларының барлык төрләрендә, тимер юл кичүләрендә авариялелек сәбәпләрен, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча эшләр торышын өйрәнү буенча эш алып бара.

3.2 Башкарма хакимият федераль органнарының Тукай муниципаль районындагы территориаль бүлекчәләренең, Тукай муниципаль районының җирле үзидарә органнарының, кызыксынган оешмаларның һәм иҗтимагый берләшмәләрнең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә хокукый җайга салуны камилләштерү, эш оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрен карый.

3.3 Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә чараларны тормышка ашыру өчен финанс һәм матди-техник ресурсларга булган ихтыяҗның нигезләнүен карый.

3.4 Муниципаль районның, авыл җирле үзидарә органнары һәм төрле оештыру-хокукый формаларындагы оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләрнең эшчәнлеген координацияли.

3.5 Юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча муниципаль максатчан программаны эшләү, тормышка ашыру һәм башкаруны контрольдә тоту мәсьәләләрен карый.

3.6 Юл хәрәкәте иминлеге проблемаларын яктырту мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара бәйләнешне гамәлгә ашыра.

3.7 Район территориясе аша узучы төбәк, федераль һәм җирле автомобиль юлларында аварияләрне бетерү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, «Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ төбәге автомобиль юллары федераль идарәсе» Федераль казна учреждениесенә һәм җирле үзидарә органнарына юллый.

3.8 Муниципаль районның һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары, предприятиеләр һәм оешмалар тарафыннан юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә закон актлары һәм башка норматив документлар, шул исәптән юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт һәм муниципаль комиссияләрнең карарларын үтәүне контрольдә тотуны оештыра һәм турыдан-туры контролдә тот.

## IV. Комиссиянең хокуклары

4.1 Тукай муниципаль районында федераль башкарма хакимият органнары бүлекчәләренең, муниципаль районның һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарының, предприятие һәм милек формаларына бәйсез рәвештә оешмаларның, иҗтимагый берләшмәләрнең вазыйфаи затларын үз утырышларына чакырырга, тыңларга һәм тиешле карарлар кабул итәргә.

4.2 Тукай муниципаль районында федераль башкарма хакимият органнарының территориаль бүлекчәләреннән, муниципаль район һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарыннан, предприятие һәм милек формасына бәйсез рәвештә оешмалардан, иҗтимагый берләшмәләрдән комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүматларны соратып алырга.

4.3 Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү эшендә җитешсезлекләрне бетерү, тәкъдим ителгән чараларны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына, җирле үзидарә органнарына, милек формасына бәйсез рәвештә предприятиеләр, оешмалар, учреждениеләр һәм иҗтимагый берләшмәләр җитәкчеләренә финанслау турында тәкъдимнәр кертергә.

4.4 Комиссия эшенә Тукай муниципаль районында башкарма хакимиятнең федераль органнары бүлекчәләрен, муниципаль районның һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарын, шулай ук фәнни, иҗтимагый һәм башка оешмаларны җәлеп итәргә.

4.5 Комиссия эшчәнлегенең аерым юнәлешләре буенча кызыксынган органнар вәкилләре һәм белгечләре арасыннан эшче төркемнәр формалаштырырга.

4.6 Юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә закон бозу билгеләре ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту мәсьәләсен хәл итү өчен хокук саклау органнарына тиешле документлар һәм материаллар җибәрергә.

4.7 Комиссия компетенциясенә кертелгән башка карарлар кабул итәргә.

## V. Комиссия эшчәнлеген оештыру тәртибе

5.1 Комиссия составы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

5.2 Комиссия үз эшчәнлеген әлеге Нигезләмә һәм комиссия утырышында ел саен кабул ителә һәм аның рәисе тарафыннан раслана торган эш планы нигезендә башкара. Аерым мәсьәләләр буенча комиссиянең эш тәртибе аның рәисе тарафыннан билгеләнә.

5.3 Комиссия составында комиссия рәисе (Башкарма комитет җитәкчесе яисә аның урынбасары), рәис урынбасары (Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге башлыгы), секретарь (Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлегенең баш белгече) һәм комиссия әгъзалары эшли.

5.4 Комиссия эшчәнлегенә рәис җитәкчелек итә, ә ул булмаганда – комиссия рәисе урынбасары, рәис комиссия эшенә җитәкчелек итә, аның эшчәнлеген планлаштыра, утырышның көн тәртибен раслый, комиссия утырышы карарын имзалый.

5.5 Комиссия утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Кирәк булган очракта чираттан тыш утырышлар үткәрелә.

5.6 Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзаларының аның утырышында катнашканда алмашу хокукы юк. Комиссия әгъзасы утырышта булмаган очракта, ул карала торган мәсьәлә буенча үз фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.

5.7 Комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы алар өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

5.8 Комиссия рәисе шәхсән чыгып, юл шартларын тикшерү буенча уртак актлар төзергә, шулай ук юл-транспорт һәлакәтләре булган урында хәлне яхшырту буенча нәтиҗәле чаралар күрергә тиеш:

һәлак булучылар белән;

ике һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган бала зыян күргән һәлакәттә;

җәяүлеләр төркемнәре катнашында һәлакәт;

пассажирлар йөртүче автобуслар катнашында, нәтиҗәдә, кешеләр һәлак булган яки зыян күргән һәлакәттә;

нәтиҗәдә кешеләр һәлак булган яки зыян күргән, хәрәкәт туктатылган тимер юл кичүендә һәлакәттә;

юл участогында 2 сәгатьтән артык хәрәкәт туктатылганда.

5.9 Комиссия әгъзалары комиссиянең эш планына юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә бәйле мәсьәләләр турында тәкъдимнәр кертә, тиешле карарлар әзерләүдә катнаша.

5.10 Комиссия утырышларын әзерләүне һәм аның карарлары үтәлеше турында мәгълүматны гомумиләштерүне комиссия секретаре башкара, ул шулай ук киңәш бирү тавышы хокукы белән комиссия эшендә катнаша. Комиссия секретаре тарафыннан соратып алына торган материаллар комиссиягә билгеләнгән вакытта тапшырылырга тиеш.

5.11 Ел саен, 10 январьга кадәр, комиссия секретаре Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе секретариатына түбәндәгеләрне үз эченә алган хисап җибәрә:

хисап елы өчен беркетмә карарлары күчермәләре;

юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе карарларын һәм Комиссия карарларын үтәү турында мәгълүмат;

Комиссиянең киләсе елга эш планы;

үзгәрешләр кертелгән очракта, комиссия составы турында мәгълүмат;

таләп буенча башка мәгълүмат.

5.12 Комиссиянең аның компетенциясе нигезендә кабул ителгән карарлары утырышларның карарлары яки беркетмәләре белән рәсмиләштерелә, аларга рәислек итүче һәм җаваплы секретарь кул куя.

5.13 Комиссия эшчәнлеге турында карарларның күчермәләре һәм башка мәгълүма утырыш уздырылган көннән соң ун көн эчендә теркәү номерын белән аның әгъзаларына һәм башка кызыксынган затларга җиткерелә.

5.14 Комиссия карарларында утырышта катнашкан комиссия әгъзалары турында мәгълүмат, утырышны үткәрү датасы, теркәү номеры, көн тәртибе, рәислек итүче һәм секретарьнең имзалары, кабул ителгән карарлар күрсәтелә.

5.15 Комиссиядә кабул ителә торган карарлар комиссия беркетмәсе яки карары рәвешендә теркәлергә һәм куелган мәсьәләләрне, башкаручыларны һәм аларны үтәү срокларын хәл итүгә юнәлдерелгән конкрет йөкләмәләр булырга тиеш.

5.16 Комиссия карарларына гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.
5.17 Комиссия секретаре Комиссия йөкләмәләрен һәм Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе карарларын (Комиссиягә кагылышлы өлештә) үтәү срокларын контрольдә тота һәм Комиссия рәисенә хәбәр итә.
5.18 Комиссия рәисе һәм урынбасары Комиссия эшчәнлеген максатчан, нәтиҗәле гамәлгә ашыру, әлеге Нигезләмә таләпләрен үтәү, Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе һәм Комиссия карарларын үтәү өчен шәхси җаваплылыкка ия.
5.19 Комиссия утырышлары материаллары һәм документлары комиссия секретарендә саклана, таләп буенча Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәт комиссиясе секретариатына бирелә.
5.20 Комиссияне матди-техник яктан тәэмин итүне Тукай муниципаль районы администрациясе башкара.